**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино,423181

Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 24 нче октябре № 2-8

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 9.04.2020 № 72-146 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 9.04.2020 № 72-146 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советында Муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 15.06.2020 № 74-151, 26.03.2021 № 9-23, 2.07.2021 № 14-35, 31.05.2022 № 25-71, 6.03.2023 № 34-101; 24.08.2023 № 40-117; 8.04.2024 № 46-137; 24.10.2024 № 50-146; карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 бүлегенең 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен.»;

1.2. Нигезләмәнең 6 бүлегенең 3 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Бу карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге
башлыгы урынбасары

СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Н.В.Назарова